**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

422750, село Большая Атня,
улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы,
Совет урамы,38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16 декабря 2024 ел № 522

**Әтнә районы Башкарма комитетының 06.08.2021 елның 252 номерлы «Индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты объектының планлаштырыла торган төзелеше турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыру мөмкинлеге турында хәбәрнамә юлламасы буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әтнә районы Башкарма комитетының 06.08.2021 елның 252 номерлы «Индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты объектының планлаштырыла торган төзелеше турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыру мөмкинлеге турында хәбәрнамә юлламасы буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Административ регламентның 3.3.3.2 пунктчасында түбәндәге эчтәлекле яңа абзац өстәргә:

"Регламентның 3.3.3.1 пунктчасында күрсәтелгән һәм шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле аерым процедураларны үтәү кысаларында Пространство белешмәләренең милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт Географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.

1.2 Административ регламентның 3.4.4 пунктчасында түбәндәге эчтәлекле яңа абзац өстәргә:

“Регламентның 3.4.4 пунктчасында күрсәтелгән һәм шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле аерым процедураларны үтәү кысаларында Пространство белешмәләренең милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт Географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә”

1.3 Административ регламентның 3.5.4 пунктчасында түбәндәге эчтәлекле яңа абзац өстәргә:

“Регламентның 3.5.2, 3.5.3 пунктчасында күрсәтелгән һәм шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле аерым процедураларны үтәү кысаларында Пространство белешмәләренең милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт Географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә”.

1.4 Административ регламентның 3.6.1 пунктчасын түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:

“3.6.1. Административ процедураны башкару өчен җаваплы вазыйфаи затның муниципаль хезмәт күрсәтүне (күрсәтүдән баш тартуны) раслый торган документ алуы административ процедураны башкара башлауның нигезе булып тора”.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат булып Татарстан Республикасы Әтнә районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы (алга таба - документлар бирү (җибәрү) өчен җаваплы вазыйфаи зат) тора.

Документлар бирү (җибәрү) өчен җаваплы вазыйфаи зат:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасы документациясен алып бару ярдәмче системасына һәм (яисә) шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмати системасына муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә белешмәләрне теркәүне һәм кертүне тәэмин итә;

мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) республика порталы аша электрон хезмәттәшлек юлы белән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен МФЦда алу мөмкинлеге турында хәбәр итә.

Процедураларны үтәү техник мөмкинлекләр булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат режимда башкарыла.

Шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле процедураларны үтәү кысаларында Пространство белешмәләренең милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт Географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар органның вәкаләтле вазыйфаи заты (орган) тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне (бирүдән баш тартуны) раслый торган документка имза салынган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мәгълүмат системаларында муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында белешмәләрне урнаштыру, мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе һәм аны алу ысуллары турында хәбәр итү.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге хокукый мәгълүматның рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (https://atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А.Ф. Каюмов